ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗВЕЗДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Улица Центральная, дом 5,
село Хорновар-Шигали, Дрожжановский
район 422465

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗВЕЗДА АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Үзәк урамы, 5 нче йорт,
Хорновар-Шигали авылы, Чүпрәле
районы 422465

Тел.: (84375) 3-65-16, 3-65-18, факс: (84375) 3-65-16, e-mail: Zvezd.Drz@tatar.ru,
www.zvezd-drogganoe.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

с.Хорновар-Шигали

26.06.2020 № 14

Йорт хайваннарын урамда йөртү
өчен урыннар билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль Закон, «Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 27.12.2018 ел, № 489-ФЗ Федераль закон, авыл җирлеге Уставы нигезендә, Чүпрәле муниципаль районы Звезда авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Звезда авыл җирлеге территориясендә йорт хайваннарын урамда йөртү өчен түбәндәге урыннарны билгеләргә:

-хуҗасы милкендә яки кулланышта булган җир кишәрлекләре;

- бордникларда һәм аларның хуҗалары күзәтүе астында кешеләр күпләп җыелмаган авыл җирлеге территориясендәге буш урыннар, торак сектор артында урнашкан урыннар:

1) Хорновар-Шигали авылының көньяк-көнбатыш өлешендә Горький урамыннан 50 метр ераклыкта;

2) Түбән урман Шигали авылының көнбатыш өлешендә Энгельс урамыннан 50 метр ;

3) Яңа Шигали авылының төньяк өлешендә Бауман урамыннан 50 метр;

4) Коршанга-Шигали авылының көнбатыш өлешендә Калинин урамыннан 50 метр;

5) Чепкас-Илмәт авылының көньяк өлешендә Колхоз урамыннан 50 метр.

2 Балалар һәм спорт мәйданчыкларында, парклар, скверлар, массакүләм ял итү урыннарында, балаларга белем бирү һәм дәвалау учреждениеләрендә, мәдәният объектларына якын территорияләрдә, кибетләрдә, хайваннар белән бергә бару өчен махсус объектлардан тыш, йорт хайваннарын иреклә йөртүне тыярга.

Әлеге пунктның гамәлдә булуы поводырь этләренә кагылмый.

3. Җирле үзидарә органы карары белән хайваннарны урамда йөртү өчен рөхсәт ителгән урыннардан читтә йөртүгә, юл куймаска.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5.Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Чүпрәле муниципаль

районының рәсми сайтында авыл җирлеге бүлегендә игълан итәргә.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Звезда авыл җирлеге башлыгы М.В. Денисова